**СОВЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

**2020 елның 19 июне** **214номер**

# КАРАР

**Матюшино авыл җирлеге чикләрен
үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар
билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Матюшино авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән хокукларын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш урында түбәндәге адрес буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә: Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Матюшино авыл җирлеге, Березовая урамы, 25 йорт 30.06.2020елның30 июне көнне, 10:00 сәгатьтә.

2. Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча тәкъдимнәр язма рәвештә түбәндәге адрес буенча кабул ителә дип билгеләргә: Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Матюшино авыл җирлеге, Березовая ур., 25 й..
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге башкарма комитетына:
    1) әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru; веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
    2) гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны, гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Матюшино авыл җирлеге
Советы рәисе** **Н.И.Миннуллина**